**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

КАРАР

2022 елның «11» апреленнән № 117

Хөкем ителүчеләрнең мәҗбүри һәм төзәтү эшләре рәвешендә җәза үтәү урыннарын билгеләү турында

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә яшәүче мәҗбүри һәм төзәтү эшләренә хөкем ителүчеләрнең Россия Федерациясе Җинаять кодексының 49, 50нче маддәләре нигезендә җәзаларын үтәү өчен, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Эш урыннары булган очракта төзәтү эшләренә хөкем ителгәннәрне эшкә урнаштырырга җибәрү өчен Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә урнашкан предприятиеләр, оешмалар һәм учреждениеләр исемлеген 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә яшәүче тоткыннар тарафыннан мәҗбүри эшләр рәвешендә җәза үтәү өчен предприятиеләр, оешмалар һәм учреждениеләр исемлеген 2 нче кушымта нигезендә расларга.

3. Хөкем ителгәннәр өчен мәҗбүри эш төрләрен 3 кушымта нигезендә расларга.

4. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы предприятиеләре, оешмалары һәм учреждениеләре җитәкчеләренә милек формаларына карамастан, төзәтү һәм мәҗбүри эшләргә хөкем ителгәннәргә эш урыннары тәкъдим итәргә.

5. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының«Төзәтү һәм мәҗбүри эшләр рәвешендә хөкем ителгәннәр тарафыннан җәза үтәү урыннарын билгеләү турында» 2018 елның 06 февралендәге 67 нче карары үз көчен югалткан дип санарга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына (икътисад буенча) йөкләргә.

Җитәкче в.б. Л.К. Исхакова

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2022 елның «11» апрелендәге
117 номерлы карарына
1 нче кушымта

Эш урыннары булган очракта төзәтү эшләренә хөкем ителгәннәрне эшкә урнаштырырга җибәрү өчен Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә урнашкан предприятиеләр, оешмалар һәм учреждениеләр исемлеге

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының авыл хуҗалыгы формированиеләре (килешү буенча);
2. «Слобода» ҖЧҖ «Яңа Чишмә коры майсыз сөт заводы» (килешү буенча);
3. «Козлова М. И.» крестьян (фермер) хуҗалыгы (килешү буенча);
4. «Вәлиев Ф.Р.» крестьян (фермер) хуҗалыгы (килешү буенча);
5. «Закрома» ҖЧҖ (килешү буенча);
6. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы «Яңа Чишмә торак – коммуналь хуҗалыгы» муниципаль унитар предприятиесе.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2022 елның «11» апрелендәге
117 номерлы карарына
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә яшәүче тоткыннар тарафыннан мәҗбүри эшләр рәвешендә җәза үтәү өчен предприятиеләр, оешмалар һәм учреждениеләр исемлеге

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы «Яңа Чишмә торак – коммуналь хуҗалыгы» муниципаль унитар предприятиесе.

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының авыл җирлекләре Башкарма комитетлары (килешү буенча)

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2022 елның «11» апрелендәге
117 номерлы карарына
3 нче кушымта

Хөкем ителгәннәр өчен мәҗбүри эш төрләре

1. штукатурно – малярные работы;
2. территориядә чүп-чар җыю;
3. үлән чабу;
4. территорияне кардан чистарту;
5. тротуарларны һәм җәяүлеләр өчен юлларны кардан һәм боздан чистарту;
6. үз территорияләрендә агач, куаклар, чәчәк түтәлләре утырту һәм аларны карау;
7. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы торак пунктлары территорияләрен төзекләндерү һәм карап тоту буенча эшләр.